**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

29 апрель 2026 ел № 480

**Нурлат муниципаль районы буенча яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләп чыгару өчен 2026 елның II кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры хакы нормативын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 03 октябрендәге 888 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы халкын сыйфатлы торак һәм торак-коммуналь хуҗалык хезмәт күрсәтүләре белән тәэмин итү» дәүләт программасының «Татарстан Республикасында яшь гаиләләрне торак белән тәэмин итү» региональ проектын гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы бәяләүчеләр берлеге» КП торак урыннарының бер квадрат метры бәясенең уртача күрсәткечен билгеләү буенча тикшеренүне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Нурлат муниципаль районы буенча яшь гаиләләргә торак сатып алу (төзү) өчен бирелә торган социаль түләүләр күләмен исәпләү өчен 2026 елның икенче кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метры хакы нормативын 61462 сум күләмендә билгеләргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин